КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 декабрь г.Казань № 1136

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче; 2016 ел, 27 апрель, 252 нче; 2016 ел, 12 май, 298 нче; 2016 ел, 10 июнь, 396 нчы; 2016 ел, 12 октябрь, 740 нчы; 2016 ел, 26 декабрь, 989 нчы; 2017 ел, 20 апрель, 232 нче; 2017 ел, 13 май, 281 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2017 ел, 21 ноябрь, 895 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1117 нче; 2018 ел, 11 июнь, 458 нче; 2018 ел, 16 ноябрь, 1002 нче; 2019 ел, 5 март, 156 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 344 нче; 2019 ел, 27 июнь, 517 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 830 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлегендәге 32 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртүче тармакларын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 28 апрель, 259 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 5 октябрь, 717 нче; 2018 ел,

5 июль, 554 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2016 – 2020 елларга» сүзләрен «2016 – 2018 елларга» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «2016 – 2020 елларга» сүзләрен «2016 – 2018 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртүче тармакларын үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2016 – 2020 елларга» сүзләрен «2016 – 2018 елларга» сүзләренә алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның исеме | «2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртүче тармакларын үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Программа)»; |

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2016 – 2018 еллар. Тормышка ашыру этаплары аерып күрсәтелми»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 6 528,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 6 528,7 мең сум:<br>(млн.сум) |

| Ел | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | |
| | | | федераль бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2016 | - | - | - | - |
| 2017 | - | - | - | - |
| 2018 | 6,5287 | 6,5287 | - | - |
| Барлыгы: | 6,5287 | 6,5287 | - | -»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру 2018 елда түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>сәнәгать җитештерүе күләмен 2015 ел дәрәҗәсенә карата 7,5 процентка арттырырга;<br>эшкәртүче тармакларда сәнәгать җитештерүе күләмен 2015 ел дәрәҗәсенә карата 6 процентка арттырырга;<br>сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртүче тармакларның өлешен 68,8 процентка кадәр арттырырга;<br>сәнәгатьтә эш белән тәэмин ителгәннәр санын 399 мең кеше дәрәҗәсендә сакларга.»; |

I бүлектә:

4 бүлекчәдә:

беренче абзацта «2020 елда» сүзләрен «2018 елда» сүзләренә алыштырырга;

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елда сәнәгать җитештерү күләмен 2015 ел дәрәҗәсенә карата 7,5 процентка арттыру;

сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртүче җитештерүләр өлеше – 68,8 процентка;»;

II бүлектә:

утыз өченче – утыз бишенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018 елда сәнәгать җитештерү күләмен 2015 ел дәрәҗәсенә карата 7,5 процентка арттыру;

эшкәртүче тармакларда сәнәгать җитештерүе күләмен 2015 ел дәрәҗәсенә карата 6 процентка арттыру;

2020 елга сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртүче җитештерүләрнең өлешен 68,8 процентка кадәр арттыру;»;

III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 6 528,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 6 528,7 мең сум:

2 нче таблица

(млн.сум)

| Ел | Акча күләме, млн.сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | |
| | | | федераль бюджеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2016 | - | - | - | - |
| 2017 | - | - | - | - |
| 2018 | 6,5287 | 6,5287 | - | - |
| Барлыгы | 6,5287 | 6,5287 | - | -»; |

VI бүлекнең 3 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 нче таблица

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Татарстан Республикасы бюджеты өчен нәтиҗәлелек | | | Федераль бюджет өчен нәтиҗәлелек | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 нче ел | 2 нче ел | 3 нче ел | 1 нче ел | 2 нче ел | 3 нче ел |
| 1. | Программаны тормышка ашыруга бюджет инвестицияләре, млн.сум | 0 | 0 | 6,5287 | 0 | 0 | 0 |
| 2. | Бюджетка салым керүләре (Ni), млн.сум | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 | 2 |
| | шулардан Программаны тормышка ашырудан керә торган салымнар | - | - | - | - | - | - |
| | табышка салым, млн.сум | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | өстәлгән кыйммәткә салым, млн.сум | - | - | - | 0 | 0 | 2 |
| | физик затларның керемнәренә салым (НДФЛ), млн.сум | 0 | 0 | 1 | - | - | - |
| | мөлкәткә салым, млн.сум | 0 | 0 | 0 | - | - | - |
| 3. | Программаның туры еллык бюджет нәтиҗәлелеге (Гбэ) | 0 | 0 | 19 | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Туры интеграль бюджет нәтиҗәлелеге (Ибэ) | - | - | 19 | - | - | 0»; |

Программага теркәлгән 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин